ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАР

«08» июль, 2019 ел, № 166

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезендә, 2017 елның 29 июнендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " Федераль закон нигезендә Күгәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Күгәй авыл җирлеге Советының 2017 елның 28 августындагы 91 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу өчен яисә аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкилнең рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. нигезләмәнең 1 пунктында "бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативы" сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урам, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Үзәк урам, 32йорт (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Күгәй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Күгәй авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф. Х. Хисаметдинова